# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге составына керүче Шама авылы торак пунктында

2019 елның 21 декабре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге составына керүче Шама авылы торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда Биләр авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән, беренче төркем инвалидлар, көндезге уку студентлары, 4 һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләр, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:
   - авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту);
   - авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү;
   - торак пунктларда урамнарны яктырту;
   - күмелгән урыннарны карап тоту һәм төзекләндерү;
   - техниканы карап тоту (трактор, килешү буенча хезмәт хакы);
   - контейнер мәйданчыклары төзү;
   - төзекләндерү (торак пунктларда агач коймаларны капиталь ремонтлау)
3. Әлеге карарны Биләр авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы, Шама авылы, Заречная урамы, 17 нче йорт адресы буенча Шама авыл мәдәният йорты бинасындагы мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Г.Г.Хәбибуллин